ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 11 2019 г. № 262

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты тарафыннан ведомствога карган учреждениеләрнең һәм унитар предприятиеләрнең контракт системасы турында законны саклау буенча сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен һәм Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты тарафыннан муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен уздыру регламентын раслау турында» 2016 елның 23 ноябрендәге 265 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 100 статьясын гамәлгә ашыру максатларында карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты тарафыннан ведомствога карган учреждениеләрнең һәм унитар предприятиеләрнең контракт системасы турында законны саклау буенча сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен һәм Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты тарафыннан муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен уздыру регламентын раслау турында» (алга таба – карар) 2016 елның 23 ноябрендәге 265 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1-нче кушымтаның 3 пунктында һәм 2-нче кушымтаның 18 пунктында:

1.1. «г» и «д» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) контрактның башлангыч (максималь) бәясен, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контракт бәясен, товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлекләренең башлангыч бәясен, товар, эш, хезмәт күрсәтү берәмлекләренең башлангыч бәясен, товар, эш, хезмәт күрсәтү бәяләренең башлангыч суммасын билгеләү һәм нигезләү дөреслеге;

д) сатып алуларның идентификацион кодлары турында һәм әлеге сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен финанс тәэминаты күләмен арттырмау турында мәгълүматның сатып алуларның план-графикларында, сатып алуларны тормышка ашыру турында хәбәрнамәләрдә, тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү беркетмәләрендә, алар белән контрактлар төзелгән контрактта катнашучылар тарафыннан җибәрелгән контрактлар проектлары шартларында, заказчылар тарафыннан төзелгән контрактлар реестрында булган мәгълүматка туры килүе;»;

1.2. «е» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. «ж» пунктчасында «алар тәкъдим иткән контракт бәясе» сүзләрен «алар тәкъдим иткән контракт бәяләре, товар, эш, хезмәт күрсәтү бәяләре суммасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. «к» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты тарафыннан ведомствога карган учреждениеләрнең һәм унитар предприятиеләрнең контракт системасы турында законны саклау буенча сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен һәм Түбән Кама шәһәре башкарма комитеты тарафыннан муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә ведомство контролен уздыру регламентын раслау турында» 2016 елның 23 ноябрендәге 265 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 10 сентябрендәге 209 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

Җитәкче Д.И. Баландин